# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТАТАР САРСАЗЫ ТОРАК ПУНКТЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

21.11.2024 ел № 2

2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең
Татар Сарсазы торак пунктында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 8 ноябрендәге 7 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы авылы гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

«2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын, төзәтү колонияләрендә җәза үтәүче гражданнарны азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

«1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Куйбышев, Елга, Урман урамнары буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, эшләр өчен шартнамә буенча түләү), Татар Сарсазы авылындагы юлларны кардан чистарту);

2) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Татар Сарсазы авылында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү буенча хезмәт күрсәтүләр).»

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Песәй авыл җирлегенең махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми

сайтында « Песәй авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы ____________ В.И.Мөхәммәтгалеев

(имза) (имзаның аңлатмасы)